РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

с. Тюлячи

КАРАР

«6» октябрь 2025ел

№ 136

Теләче муниципаль районында 2026 елга балаларга өстәмә белем бирүче туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм мәдәният юнәлешендәге мәгариф оешмаларының һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күппрофильле белем бирү оешмаларының өстәмә белем бирү программасын тормышка ашыру өчен норматив чыгымнарны раслау турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 99 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 31 декабрендәге 939 номерлы «Татарстан Республикасы туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлештәге балаларга өстәмә белем бирү мәгариф учреждениеләрен һәм Татарстан Республикасы балаларына өстәмә белем бирүнең күп профильле мәгариф учреждениеләрен финанслау нормативларын исәпләү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» карары нигезендә, ДБУ «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» нең 2025 елның 26 сентябрендәге 01/1608 номерлы хатын карап, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2026 елга расларга:

1.1. Теләче муниципаль районында балаларга өстәмә белем бирүче туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм мәдәният юнәлешендәге мәгариф оешмаларының һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күппрофильле белем бирү оешмаларының өстәмә белем бирү программасын тормышка ашыру өчен норматив чыгымнарны, 1 номерлы кушымта нигезендә;

1.2. Теләче муниципаль районының өстәмә белем бирү оешмаларында инклюзив белем бирү оештыру юлы белән сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән, инвалид укучылар өчен өстәмә гомуми үсеш программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнарны, 2 номерлы кушымта нигезендә;

1.3. балаларга өстәмә белем бирүче туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм мәдәният юнәлешендәге мәгариф оешмаларының һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күппрофильле белем бирү оешмаларының өстәмә белем бирү программасын тормышка ашыру өчен норматив чыгымнарны төзәтмәләр коэффициентын 0,9 күләмендә.

2. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының Финанс-бюджет палатасына (Яхин Р.Р.) балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының әлеге карарның 1 пунктында расланган норматив чыгымнары нигезендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«6» 10 2025 № 136
карарына 1 номерлы кушымта

Теләче муниципаль районында балаларга өстәмә белем бирүче туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм мәдәният юнәлешендәге мәгариф оешмаларының һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күппрофильле белем бирү оешмаларының өстәмә белем бирү программасын тормышка ашыру өчен норматив чыгымнар

| Өстәмә белем бирү программасы юнәлеше | Территориаль урнашу | 1 укучыга елына норматив чыгымнар, сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | беренче уку елы | икенче уку елы | өченче һәм аннан соңгы уку еллары |
| Сәнгать-эстетик | авыл җирлеге | 9 541 | 17 242 | 20 590 |
| Физкультура-спорт | авыл җирлеге | 9 441 | 17 142 | 20 490 |
| Техник иҗат | авыл җирлеге | 9 941 | 17 642 | 20 990 |
| Туристлык-туган якны өйрәнү | авыл җирлеге | 9 541 | 17 242 | 20 590 |
| Экология-биология | авыл җирлеге | 9 541 | 17 242 | 20 590 |
| Хәрби-патриотик | авыл җирлеге | 9 541 | 17 242 | 20 590 |
| социаль-педагогик һәм икътисадый | авыл җирлеге | 9 341 | 17 042 | 20 390 |
| Табигый-фәнни | авыл җирлеге | 9 541 | 17 242 | 20 590 |

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«6» 10 2025 № 136
карарына 2 номерлы кушымта

## Теләче муниципаль районының өстәмә белем бирү оешмаларында инклюзив белем бирү оештыру юлы белән сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән, инвалид укучылар өчен өстәмә гомуми үсеш программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнар

| Өстәмә белем бирү программасы юнәлеше | Территориаль урнашу | Елына норматив чыгымнар, сум | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | терәк-хәрәкәт аппараты бозылган, психик үсешләрендә тоткарлык булган, аутистик спектры тайпылышлары булган һәм үсешендә күпсанлы бозылулар булган бер укучыга | | | бер укучыда ишетү сәләте бозылганда: ишетмәүчеләр, начар ишетүчеләр, соңрак ишетмәүчегә әйләнүчеләр | | |
| | | беренче уку елы | икенче уку елы | өченче һәм аннан соңгы уку еллары | беренче уку елы | икенче уку елы | өченче һәм аннан соңгы уку еллары |
| Сәнгать-эстетик | авыл җирлеге | 19520 | 32068 | 35416 | 13864 | 23719 | 27067 |
| Физкультура-спорт | авыл җирлеге | 19420 | 31968 | 35316 | 13764 | 23619 | 26967 |
| Техник иҗат | авыл җирлеге | 19920 | 32468 | 35816 | 14264 | 24119 | 27467 |
| Туристлык-туган якны өйрәнү | авыл җирлеге | 19520 | 32068 | 35416 | 13864 | 23719 | 27067 |
| Экология-биология | авыл җирлеге | 19520 | 32068 | 35416 | 13864 | 23719 | 27067 |
| Хәрби-патриотик | авыл җирлеге | 19520 | 32068 | 35416 | 13864 | 23719 | 27067 |
| Социаль-педагогик һәм икътисадый | авыл җирлеге | 19320 | 31868 | 35216 | 13664 | 23519 | 26867 |
| Табигый-фәнни | авыл җирлеге | 19520 | 32068 | 35416 | 13864 | 23719 | 27067 |